

Совет гаскәрләренен Афганистаннан чыгарылуына 30 ел тулу унаеннан Мордовиядә торле чаралар vткәрелде. Истәлекле дата кин билгеләнде.

Тагы бер мисал. 2019нчы елнын 13 февралендә Ләмберә районы  Большая Елховка авылында Афганистаннан Совет гаскәрләренен чыгарылуына утыз ел тулу унаеннан митинг vткән. Чарада социаль мәсьәләләр буенча район главасы урынбасары Р.Х.Салимова, Большеелховка авылы главасы Ю.С.Зеленцов, «Боевое братство» ижтимагый оешманын район бvлеге рәисе М.Н.Салеев, район хәрби бvлек житәкчесе ярдәмчесе Р.Х.Севкаев, «Большеелховская СОШ» директоры А.М.Афроськин, Ләмберә районы ветераннары Советы әгъзасы Р.Д.Кряков, Б.Елховка авылы ветераннары Советы житәкчесе Н.И.Литюшкин һәм Ләмберә районы сугышчы-интернацио-налистлары: Марат Хайдар улы Рагузин, Наиль Касим улы Вагапов, Рәстәм Раис улы Серебряков, Камиль Абдрашит улы Заликов, Олег Иванович Белоглазов, Игорь Александрович Сухов һәм башкалар катнашында vткән.



Афганистанда Ләмберә районыннан 79 кеше хезмәт иткән. Аларнын кvбесе кvрсәткән батырлыклары очен орден һәм медальләр белән бvләкләнгәннәр.

Шул ук конне Ләмберә админи-страциясенен зур залында шул ук теманы яктырткан тантаналы чара vткән. Приказ vтәп, батырлыклары очен «Кызыл Йолдыз» ордены белән бvләкләнгән татар милләтле Ләмберә афганчысы - Марс Нәсрулла улы Ахметов һәм Черемиштән Ринат Шамиль улы Альмяшев, «Батырлык очен» («За отвагу») медале алган Большая Елховкадан Юнир Ильяс улы Мамеев һәм Аксеннан Рафаэль Няим улы Алимов, Звездный авылыннан Марат Хайдар улы Рагузин һәм башка хормәтле сугыш ветераннары чарада булган. Бу тантаналы кичәдә республика афганчылары авыр хәрби хезмәт елларын, сугышчан дусларын искә алдылар. Ветераннар vзләре белән булган вакыйгалар турында сойләде, балаларнын сорауларына жавап бирде. Мондый

хөрмәтләvләр vсеп килvче яшь буынга патриотик тәрбия бирv өчен ин унай булуын әйттеләр.